**Милләт җыены**

# *Конгрессның эше корылтай белән генә бәяләнми*



**Сулдан уңга: Самар шәһәр татар милли—мәдәни мохтарияте рәисе Рифкат Хуҗин, Байканурда «Туган тел» җәмгыятен ачкан Мәгариф Раянов, Самар татар милли хәрәкәте ветераны Шамил Баһаутдин, Мордовиядән Акмаев, татар хәрәкәтенең идеологы Азат Надиров, Самар өлкә татар милли-мәдәни мохтарияте мөдире Равил Галимов.**

2012 елның декабре татар дөньясы өчен Дөнья татарларының бишенче корылтае белән тарихка керде. Биш елга бер мәртәбә уза торган бу чара гомер-гомергә мәдәни-сәяси чара итеп кабул ителә.

Үлчәүнең бер ягына мәдәниятны, икенче ягына сәясәтне куйсак, әлбәттә инде, соңгысы авыррак булачак. Кайсы гына корылтайны алма, күзәтүчеләр икегә бүленә. Ак һәм кара төсләргә. Алдагы татар җыеннарыннан канәгатьсез булган Фәүзия ханым Бәйрәмова бу юлы: "Алдагыларында демократия булган икән әле", диде. Шуңа күрә, нәрсәнедер бәяләргәндә вакыт берәмлеген дә исәпкә алырга кирәктер. Корылтай узды. Делегатлар төбәкләргә таралыштылар. Хисләр суынды. Сөт белән каймак аерылды. Хәзер суык хис белән вакыйгага бәя дә бирергә була. Самар төбәгеннән төрле яшьтәгеләр барды. Сыйнфый күзлектән дә палитра бүгенге чынбарлыкны тасвирлый.

Әңгәмәдәшебез, Самар өлкә татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе, соңгы 90 ел эчендә кискен сәяси көрәштә Самар шәһәр Думасына депутат булып узган, милли хәрәкәтнең эчендә кайнаган, ике малай атасы, эшбатыр, тирән акыл иясе, әвыл җирлегендә татар гаиләсендә тәрбия алган, үз кулы белән ташпулат салып кергән, чын татар ире Мидхәт углы Минхәмәт Хәлиуллов.

**- Гомерегездә беренче мәртәбә Дөнья татар конгрессының корылтаенда катнаштыгыз. Иң көчле тәэсирләрегез?**

- Мин үзем эш кешесе буларак, аның купшылыгына артык игътибар итмим. Ләкин дә бу очракта купшылык та кирәк.

Без - читтәгеләр, эшкә генә түгел, рухи нигезебезгә дәрт алырга да кайтабыз. Фикерләремне хронология буенча бирсәм, җайлырак булыр сыман.

**- Алайса, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрыннан башлыйбыз.**

- Ринат Закиров үзенең чыгышында ветераннарны искә алудан башлады. Беренчедән, ул Самар өлкәсеннән башлады һәм төбәгебездә 25 ел буена милләтебезгә хезмәт иткән Шамил Баһаутдин, Илгиз Кәлүч, Азат Надировларны атады. Конгресска 20 ел булса, Самар төбәгендәге "Туган тел" җәмгыятенә 25 ел. Без биш ел конгрессыз эшләдек. Әлбәттә инде, конгрессның Башкарма комитеты эшләгән эшләрнең барчасына да тукталып узмады. Ул мөмкин дә түгел. Татар авылларындагы мәктәпләрдә «Әлифба»ны үзәк алып ташлагач, көрәш бик каты барды һәм «Әлифба»ны кире кайтара алдык. Мәктәпләргә православ динен кертергә зур тырышлык күрсәттеләр атакайлар. Җиңеп чыга алдык. Самар төбәгендә беренче мәртәбә федераль күләмдә ат чабышлары, авыл Сабан туе, «Түгәрәк уен» узды! Башка милләтләр алдында бу чаралар татарның дәрәҗәсен нык үстерде. Сабан туйлары Тын Океанга барып җитте. Андый зур мәшәкатьләрне үзе уздырган кеше генә белә.

**- Ә бит конгрессны мәдәни чараларның күп булуы белән чыбыркылыйлар.**

- Мәдәни чаралар күп була алмый. Мәдәни чара - ул халык белән сөйләшү мәйданы. Безгә халык белән элемтәне югалтырга ярамый. Һәм нинди сәяси шартларда эшләгәнне исәпкә алырга кирәк. Туксанынчы елларда сөйләгәнне бүген яңгыратып булмый. Бик нәзберек эш алып барып, бер-беребезне сакларга тиешбез. Конгресс җир шары буенча сибелгән татардан олуг бер татар мохитен тудырып, бер-беребезгә дәрт вә дәрман биреп яши.

**- Сәхнәдәге барлык чыгышлар да югары сыйфатта булмады бит. Аны танырга кирәктер?**

- Анысына Закиров түгел, чыгып сөйләүче гаепле. Әлбәттә, Башкортостаннан килеп, татар турында урысча сөйләү бер калыпка да сыймый. Дересе: ул ханым татар турында да сөйләмәде. Корылтайның дәрәҗәсен Башкортостан вәкиле нык төшерде, монысы хак.

**- Тантана башланыр алдыннан опера театрында халык бик озак аралашты. Сез үзегез моңа ничек карыйсыз?**

**(Ахыры 8нче биттә)**

Парлы буласыгыз килсә, "Алеф"ка килегез!



Дөнья мәшәкатьләренә чумып, үз тормышыгызны онытып җибәрмәгез.

Никадәр генә мул тормышта яшәсәгез дә, һөнәр иясе булсагыз да, торак урыныгыз яхшы булса да - бу әле чын бәхет түгел.

Чын бәхет - ул эштән арып кайткач, сөйгәнеңнең елмаеп каршы алуы, кичләрен бергәләп сөйләшеп утыру, төннәрен хисләргә хозурлану.

Ходай Тәгалә барлык тереклекне парлы иткән.

Парлы яшәү - ул кешенең яшәешенә нур өсти, тормыш-көнкүрешен җиңеләйтә, адәмнең гомерен озынайта.

Тулырак мәгълүматны түбәндәге телефон аша белә аласыз:

**8-919=800-01-49.**

"Алеф" фирмасының максаты бер - татар-башкортларны гаиләле итү, бәхетле итү.

**Наше будущее**

# У нас в гостях «Яктылык»

Духовное управление мусульман Самарской области и Самарская Соборная мечеть 11 декабря впервые организовали курбан-меджлис для учащихся татарской школы «Яктылык».

В столовой мечети накрыли стол с угощениями, блюдами из мяса курбана и после намаза пригласили туда детей.

Программа включала в себя проповеди имамов, выступление муфтия Самарской области, рассказы о празднике и традициях Ислама.

Хазраты прочли суры из Корана.

В заключение служители мечети подарили специально приготовленные подарки: брошюрки про курбан и календари на 2013 год.

То, что мы вкладываем в детей, ту любовь, ту доброту, милосердие, мы и получим в будущем. Мы постарались, чтобы дети почувствовали ту же радость, что и взрослые. У нас было около 120 детей, праздник удался.

Муфтий поблагодарил всех, принял участие в подготовке мероприятия и выразил надежду, что это станет традицией, чтобы дети легче приобщались к духовным ценностям и, также как взрослые, с нетерпением ждали этот праздника.

Курбан-байрам - главный праздник в Исламе. Он знаменует окончание паломничества в Мекку и олицетворяет ценности, составляющие суть Ислама - добро, милосердие, любовь, сострадание, заботу о ближних.

**Ректор медресе «Нур»**
**Али СУЛЕЙМАНОВ.**

**Новизна**

# Совет улемов

В Исламе прописаны все правила и нормы для успешного проживания на этом свете и достойной подготовки к будущей, вечной жизни. Однако еще значительное число наших собратьев татар, этнических мусульман, проживают вне поля Исламской морали.

Общеизвестно, что воспитание человека - ключевая проблема любого цивилизованного общества. Любой человек, его семья и общество, в котором он проживает, оцениваются согласно уровня их воспитанности.

При этом нельзя забывать то, что качественной может быть только та система воспитания, которая ориентирована на общечеловеческие ценности, то есть на божественные нормы морали. К сожалению, в нашем обществе религиозное сознание населения находится на довольно низком уровне и подорваны национальные и культурные традиции. Многие живут без Аллаха в душе и в голове.

В связи с этим в Духовном управлении Самарской области разрабатывается комплексная программа по развитию Исламского просвещения, изучения основ Исламской этики и морали, религиозных традиций согласно ханафитского мазхаба.

Над разработкой подобной программы и претворению ее в жизнь трудятся имамы, входящие в совет улемов.

19 декабря 2012 года состоялось очередное собрание улемов.

Среди вопросов, рассмотренных на этом совете были:

- анализ этических норм пребывающих в мечети;
- экскурсии по мечети разрешать только в присутствии духовного лица;
- подготовить кинородик для проведения экскурсий;
- собрать экскурсоводов и провести с ними мастер-класс;
- собрать религиозных лидеров различных мусульманских народов, проживающих на территории Самарской области, и наладить сотрудничество с ними;
- подготовить сборник проповедей имамов для издания специальной книги.

**Фарид ШИРИЯЗДАНОВ.**

**Концерт**

## *Күңелләрегезне канатландырып алыгыз*

*Гыйнварның 12ндә (шимбә) көндезге сәгать өчтә "ЧАЙКА" Мәдәният Сараенда (Управленческий бистәсе) "Ялкынлы яшьлек" ансамбле 2013 елга багышланган өр-яңа концерт программасын күрсәтә.*

**Билет бәясе - 100 һәм 200 сум. Билетлар "Чайка" Мәдәният Сараенда һәм Литвинов Мәдәният Сараенда сатыла.**

Белешмәләр өчен телефоннар:
**8-927=608-76-43**
**8-927=200-81-59**